ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октября, з/у1Б,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Октябрь урамы, 1Б йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 1 «31» январь 2020г.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Бәйрәкә авыл
җирлегендә "2020 елга җирләү
буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең хакын раслау турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 санлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы "2020 елда пособиеләр һәм компенсация түләүләр күләмен индексацияләү һәм раслау турында "гы 61 санлы карары нигезендә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р и т ә:

1.2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6 124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми порталында һәм ул Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы А.О. Әхмәтшина

Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге
башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы
1 санлы карарына
№1 кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР
Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә
авыл җирлегендә җирләү
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
ХАКЛАРЫ

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Күмү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 530,46 |
| Мәетне (калдыкларны) зыяратка кадәр илтү | 718,89 |
| Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 875,51 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге
башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы
1 санлы карарына
№2 кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР
Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә
авыл җирлегендә җирләү
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
ХАКЛАРЫ

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе( сумнарда) |
|---|---|
| Күмү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1950.15 |
| Мәетне (калдыкларны) зыяратка кадәр илтү | 718,89 |
| Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 875,51 |
| Мәетне төрү | 580.31 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |